Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение гимназия с. Раевский

**СОГЛАСОВАНО**
на заседании ШМО учителей
башкирского языка и татарского языка
Протокол №1
от «26» августа 2016г.

**РАССМОТРЕНО**
на заседании
научно - методического
совета
Протокол №1
от «29» августа 2016г.

**УТВЕРЖДАЮ**
Директор МБОУ гимназия
с. Раевский
__________________Колеганов С. Н.
Приказ №
от «29» августа 2016г.

# Рабочая программа

## по родному языку

## в 9В классе

Срок реализации: 2016 -2017 учебный год

Составитель: учитель татарского языка и литературы Насырова Л.М.

Составлено на основе программы по татарскому языку и литературе («Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программалары»,Казан, «Мәгариф», 2010 )

2016 год

ЭЧТӘЛЕК

I. Аңлатма язуы.
II. Укыту предметына гомуми аңлатма.
III. Укыту предметының укыту планында тоткан урыны.
IV. Укытуның гомуми, шәхси, метапредмет нәтиҗәләре.
V. Укыту предметының төп эчтәлеге
VI. Укыту предметының сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча  планлаштырылган нәтиҗәләре.
VII. Укыту предметының темаларга якынча бүленеше.
VIII. Укытуны материаль-техник һәм мәгълүмати яктан тәэмин итү.

Аңлатма язуы

Эш программасы статусы

Эш программасы түбәндәге документларны исәпкә алып төзелде:

1. “Мәгариф турында” Россия Федерациясенең Законы (“Закон об образовании” Закон Российской Федерации)

2. “Мәгариф турында”  Башкортостан Республикасы Законы.

3. Гомуми белем эчтәлегенең мәҗбүри минимумы

4. ”Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы” 1-11 нче сыйныфлар. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2010нчы ел.

5.Раевка авылы гимназиясенең  2015-2016 нчы уку елына расланган укыту планы

6. Дәреслек: Р.Ә. Асылгәрәева, М.З. Зиннәтовна ”Татар теле”  7 нче сыйныф, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2010нчы ел.

Соңгы елларда республикада татар теленең куллану даирәсе киңәйде, иҗтимагый функциясе көчәйде. Милләтара мөнәсәбәтләрне якынлаштыручы, җайга салучы чара буларак та аның мөмкинлекләре үсте. Укучыларда лингвистик(тел), аралашу(коммуникатив), этнокультура өлкәсенә караган (культурологик) компетенцияләр булдыру рус мәктәбендә татар теленә өйрәтүнең максатын тәшкил итә.

Лингвистик компетенция (укучыларның ана телелннән мәгълүматлылыгы) фонемалар, морфемалар, сүз ясалышы, сүзтезмәләр, җөмләләр, җөмлә кисәкләре, лексик һәм грамматик берәмлекләр, лингвистик анализны һ.б. үз эченә ала.

Аралашу (коммуникатив) компетенциясе ул – башкалар әйткәнне аңлау һәм үз фикереңне белдерү өчен тупланган белем, осталык, күнекмәләр җыелмасы; хәзерге татар теле нормаларына ия булу, сүз байлыгын, сөйләмнең грамматик ягын дөрес итеп үзләштерү; телдән һәм язма формада бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен булдыру һ.б.

Этнокультура өлкәсенә караган (культурологик) компетенция, ягъни телне милли-мәдәни яссылыкта үзләштерү ул – укучыларны сөйләмгә милли үзенчәлекләрне чагылдырган текстлар белән эшләү, тормыш-көнкүреш, гореф-гадәт үзенчәлекләрен, сынлы сәнгать әсәрләрен, халык авыз иҗаты үрнәкләрен белү, татар сөйләм этикетына ия булу.

Рус мәктәбендә ана теле буларак татар теле укытуның төп бурычлары түбәндәгеләр:

1. Татар телен өйрәнүгә карата башлангыч сыйныфларда нигез салынган кызыксынуны көчәйтү, үз милләтеңә, телеңә хөрмәт белән карау, шулай ук татар теле аша башка милләт вәкилләренә, аларның рухи мирасына мәхәббәт хисе тәрбияләү.
2. Татар теленең барлык тармаклары буенча эзлекле рәвештә фәнни белем бирү.
3. Сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча ныклы күнекмәләр булдыру. Туган телдә матур һәм дөрес аралашырга өйрәтү.
4. Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләрен камилләштерү. Көндәлек тормышта татар теле мөмкинлекләреннән тулысынча файдалана белергә өйрәтү.
5. Туган тел аша өзлексез белем һәм тәҗрибә туплау.
6.Татар телен башка фәннәрдә белем алу чарасы буларак кулланырга өйрәтү күнекмәләрен булдыру.
7. Татар теле, аның төзелеше, кулланылышы турында мәгълүмат алу; татар әдәби теленең төп нормаларын һәм стилистик мөмкинлекләрен ачык күзаллау, аларны тиешенчә куллана белү; сүз байлыгын арттыру, сөйләмдә кулланыла торган грамматик чараларны төрләләндерү.
8. Укучыларны даими рәвештә татар милли мәдәнияте мирасына тарту.
9. Татар теле дәресләрендә, белем бирү белән бергә, тәрбияви бурычларны онытмаска кирәк.
10. Телне өйрәнгәндә үзләштергән белем һәм күнекмәләрне гамәлдә дөрес куллана белү.
11. Укучыларның логик фикерләү сәләтен үстерү.
12. Дәреслек, өстәмә һәм белешмә әдәбият белән эш итү, уку, язу күнекмәләрен камилләштерү.

Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларының күбрәк рус телендә аралашуларын һәм фәннәрнең рус телендә үзләштерелүен истә тотып, темаларны үткәндә, грамматик категорияләрне аңлатканда, татар теленә хас күренешләрне рус теле белән янәшә куеп (сопостовительная грамматика) аңлату нәтиҗәле.

Укучыларның гомуми грамоталылыгын тикшерү һәм үстерү өчен төрле характердагы диктантлар, шулай ук сүзлек байлыгын арттыру, бәйләнешле сөйләм үстерү, логик фикерләү дәрәҗәсен камилләштерү максатыннан сочинение һәм изложениеләр яздырыла.

Эш программасы тел һәм әдәбият темаларын берләштерелеп төзелде, чөнки дәрес 2015-2016 нчы уку елына расланган укыту планында "Туган тел" буларак бирелә.

.

Укыту предметына гомуми аңлатма

1.Татар теле һәм әдәбиятын укыту максатлары

Танып белү максатының эчтәлеге

Башкортостан Республикасында яшәүче һәр милләт кешесенә, үз халкы тарихыннан тыш, шушы төбәктә төп халык булып саналгантатархалкымәдәниятен, гореф-гадәтләрен, тарихиүткәнен, бүгенгесен, киләчәгенбелүзарур. Татархалкыбеләнкулга-култотыныпяшәргәәзерләнүчеһәркешебухалыкның бәйрәмнәрен, традицияләренаңларга, хөрмәтитәргә, әдәбият-сәнгатьвәкилләренең иҗадиказанышларыбеләнүзенең рухиүсешенбаетаалумөмкинлегеннәнфайдаланыргатиеш. Программаэчтәлегетелгәөйрәтүпроцессынбалаөчен "башкадөньягатәрәзәачу" булырлыкһәмшуның аркылыаның үзяшәешендәтулыракаңлавынаярдәмитәрлекитепсайланды.

Урта баскычта татар халкының рухи дөньясын чагылдырган, тормыш – көнкүрештәге әхләкый проблемаларны үз эченә алган, укучыларның кызыксынуларына, яшь үзенчәлекләренә туры килгән әдәби әсәрләрбелән танышу;Татарстандаяшәүчемилләтләр, Татарстанның дәүләтсимволлары, Татарстанның территориясе, географикурыны;башкалабызКазанның тарихи үткәне, бүгенгейөзе;татарсәнгатенең төрлетармакларыбуенчакүренеклешәхесләр турында укучыларның татарчасөйлиалуларытөпмаксатитепкуела.

Югары баскычта укучылар 1-9 сыйныфларда алган белемнәрен тагын да тулыландыралар, киңәйтәләр, гомумиләштерәләр. Урта баскычта өйрәнелгән темаларга өстәп, укучыларны Башкортостанның сәнәгый-икътисади, фәнни һәм мәдәни үсеш дәрәҗәсе, халыкара элемтәләре, Россиядә һәм дөнъяда тоткан урыны, яшьләр арасындагы мөнәсәбәтләр һәм спорт казанышлары турында иркен аралашуга чыгару максат итеп куела.

Үстерү максатының эчтәлеге

Шәхеснең белемлебулуы, тәрбиялелек һәм анын фикерләүсәләтеүсешедәрәҗәсеннән дәтора. Укытупроцессындаүстерү, тәрбиямаксатларындаимикүзаллапэшләү –укытуның практикягыуңышлылыгының алшарты. Балаларның психикүсешентүбәндәгеюнәлешләрдәүстерүгәаеручаигътибарбирүталәпителә:

– фикерләүнеүстерүбеләнбәйлепсихикфункцияләр: логикфикерләү, сәбәп-нәтиҗәбәйләнешләрентабу, индуктив, дедуктивфикерләү;

– хәтернеүстерү (ихтыярый, ихтыярсыз), игътибарлылыкныүстерү;

– аралашабелүсәләтенүстерү (аралашучанлык, хисләлек, эмпатияхисләре);

– ихтыяр көче, максатчанлык, активлыккебексәләтләрнеустерү.

Программагасайланганэчтәлекнигезендәсөйләмэшчәнлегенең барлыктөрләребуенчадаэшоештырганда,бумаксатларберенчеплангакуела.

Тәрбияви максатның эчтәлеге

Укучыларның тиешледәрәҗәдәгетәрбиялелегеннәнбашкаукытупроцессыноештырумөмкинтүгел. Тәрбияпроцессы, беренчечиратта, укытуның эчтәлегеһәмметодларыбеләнбәйле. Шуңакүрәпрограммаэчтәлегенсайлаганда, материалның тәрбиявимөмкинлекләренисәпкәалу мөһим.Эчтәлектәәхлакыйпроблемаларбулгантекстларүзләреүккоммуникативмотивациягәия, шунлыктанаралашуситуациясебулдыруәлләникыенлыктудырмый. Башкамилләтвәкилләренең күңеленяулардай, алардагомумкешелекәхлакыйсыйфатларнытәрбияләрдәйтатарәдәбиятыөлгеләребеләнтаныштырудашушыукмаксаткабуй сындырыла,сөйләшү-аралашугаалыпчыгугакулайракбулганәдәбиәсәрләртәкъдимителә.

Белем бирү максатының эчтәлеге

Укучыларның татартелебуенчалексик, грамматиккүнекмәләрефилологикбелемнәрсуммасыдәрәҗәсендәгенәкалмыйча, әсөйләмэшчәнлегенең барлыктөрләрендәдәаралашудакулланырлыкдәрәҗәгәҗитүезарур. Ягъни, укучылар, ниндидәбулсасүзне, яграмматиккатегориянетану, аеру, аңлау, тәрҗемәитүдәрәҗәсендәгенәтүгел, аларныаралашумаксатыннанмөстәкыйлькулланырлыкдәрәҗәдәөйрәнергәтиешләр. Шулвакыттагынататартелендәүләттелебуларакөйрәнүбурычыүтәлә.

## Укытуның гомуми, шәхси, метапредмет нәтиҗәләре

Төп һәм (урта)гомуми белем бирү мәктәбендә телне гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда татар теленең күп мәдәниятле дөньядагы роле һәм мөһимлеге турында күзаллаулар формалаша. Татар мәдәниятенең укучылар өчен булган катламы белән танышу башка мәдәнияткә карата ихтирам хисе уята, ягъни укучыларга үз мәдәниятләрен дә тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә, аларда ватанпәрвәрлек хисе уята.

Төп һәм урта (тулы) гомуми белем бирү баскычларында татар теленә өйрәтүнең программада күрсәтелгән күләмдә гомуми нәтиҗәләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

– укучыларныңкоммуникатив компетенциясен(аралашу осталыгын) үстерү, ягъни татар телендә сөйләшүчеләр белән телдән яки язмача аралашукүнекмәләре булдыру;

– коммуникатив бурычлар куя һәм хәл итә белү, адекват рәвештә арашуның вербаль һәм вербаль булмаган чараларыннан, сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдалана алу, итагатьле һәм киң күңелле әңгәмәдәш булу;

– “Татар теле һәм әдәбияты” фәненәкарата уңай мотивация һәм тотрыклы кызыксыну булдыруһәм шулар нигезендә белем алуның алдагы баскычларында татар телен уңышлы үзләштергә шартлар тудыру.

## Укытуның шәхси нәтиҗәләре

Төп һәм урта (тулы) гомуми белем бирү баскычларын төгәлләгәндә,укучының үзенә һәм үзенең әйләнә-тирәсендәге кешеләргә, тормыштагы яшәеш проблемаларына карата түбәндәге шәхси кыйммәтләре формалашкан булуы күзаллана:

– шәхесара һәм мәдәниятара аралашудататар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;

– әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;
– әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомүмкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;
– “гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек”,төшенчәләрен кабул итү, “башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык”, “кеше кадерен белү” кебек хисләр формалашу.

## Укытуның метапредмет нәтиҗәләре

Төп һәм(урта) белем бирү баскычларындататар теле һәм әдәбиятын укыту, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (*танып-белү, регулятив, коммуникатив)*формалаштыругахезмәт итә.

Укучыларда мәгълүмати җәмгыятьтә яшәү һәм эшләү өчен кирәкле күнекмәләр үстерелә. Укучылар текст, күрмә-график рәсемнәр, хәрәкәтле яисә хәрәкәтсез сурәтләр, ягъни төрле коммуникацион технологияләр аша тапшырыла торган мәгълүмати объектлар белән эшләү тәҗрибәсе ала; презентацион материаллар әзерләп, зур булмаган аудитория алдында чыгыш ясарга өйрән*ә; у*кучыларда, компьютер яисә ИКТ нең башка чаралары белән эш иткәндә, сәламәтлеккә зыян китерми торган эш алымнарын куллана алукүнекмәләре формалаша.

*Танып-белүнәтиҗәләре:*
– фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
– иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру;
– объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;
– төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;
– тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллану.

*Регулятив нәтиҗәләр*:
– уку хезмәтендә үзенә максат куя, бурычларны билгели белү;
– эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;

– уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;
– билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү;
– укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;
– ихтыяр көче,максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;
– дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли һәм алар белән дөрес эш итә белү;
– дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү.

*Коммуникатив* нәтиҗәләр:

– әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;
– әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү;
– аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре);
– парларда һәм күмәк эшли белү;
– мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару;
– әңгәмәдәшең белән контактны башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.

## Укыту предметының төп эчтәлеге

Белем бирү эчтәлегенең мәҗбүри минимумы.

Коммуникатив компетенция.

Сөйләм. Телдән һәм язма сөйләм. Диалогик һәм монологик сөйләм. Сөйләм стильләре. Матур әдәбият теле.

Телдән һәм язма сөйләмне аеру. Тел берәмлекләрен аралашуны ситуация үзенчәлекләренә карап сайлый белү. Аралашу өлкәсенә һәм ситуациясенә бәйле рәвештә телдән һәм язма сөйләмне дөрес файдалану.

Текстның темасы, төп фикере һәм төзелеше. Аларның стильләрендә жанр төрлелеге.

Татар әдәби теле һәм аның нормалары турында төшенчә.

Сөйләм эшчәнлеге төрләрен ( тыңлап аңлау, сөйләү, уку һәм язу) үзләштерү.

Укуның төрле төрләрен (танышу, өйрәнү һ.б.) үзләштерү. Уку китаплары, масса күләм мәгълүмат чаралары, интернет һ.б. чаралар белән эшләү алымнарын үзләштерү.

Иҗтимагый - мәдәни, әхлакый, көнкүреш,, уку темаларына бәйле булган монологик һәм диалогик сөйләм үрнәкләрен төзү.

Текстның эчтәлеген кыскача, тулы яки сайлап алып сөйләү. Диктантлар, изложениеләр һәм сочинениеләр язу. Төрле стиль һәм жанрдагы текстлар төзү: бәяләмә, аннотация, хат, ышаныч кәгазе, гариза, тезис, конспект һ.б.

Лингвистик компетенция. Телнең кеше тормышында һәм җәмгыятьтә тоткан урыны. Татар теле – Татарстан Республикасының дәүләт теле. Татар теле – татар халкының милли теле.

Матур әдәбият һәм аның нормалары турында төшенчә.

Татар теленең үсештә булуы. Соңгы елларда татар теле лексикасындагы үзгәрешләр.

Тел белеменә караган сүзлекләр һәм алардан файдалану.

Яңа уку елы башына укучыларның белем, осталык һәм күнекмәләренә кыскача характеристика.

Фонетика:

1. Сузык һәм тартык авазларның классификациясен, алардагы үзгәрешләрне белү. Сингармонизм законын, рәт һәм ирен гармониясе үзенчәлекләрен сөйләмдә дөрес куллану.

2. Татар телендә иҗек калыплары, сүзләрне дөрес басым белән әйтү. Җөмләдә логик басымны дөрес билгеләү, тиешле интонация белән сөйләү.
3. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Алфавитны истә калдыру.
4. Сүзләргә фонетик анализ ясау.
5. Орфоэпик сүзлекләрдән файдалану.

Лексика һәм фразеология:

1. Татар теленең сүзлек составын килеп чыгуы, кулланылу өлкәсе һәм кулланылу дәрәҗәсе буенча бәяли белү.
2. Сүзләрне һәм фразеологизмнарны урынлы куллану, аларның мәгънәләренә аңлатма бирә белү. Синоним, омоним, антоним сүзләрне дөрес куллану.
3. Төрле типтагы сүзлекләрдән файдалана белү.

Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы:

1. Сүзләрнең мәгънәле кисәкләренә аңлатма бирә белү. Тамырдаш сүзләр табу. Сүзләрне төзелеше һәм ясалышы буенча тикшерү.
2. Татар телендә сүзләрнең ясалыш ысулларын белү.

Морфология:

1. Сүз төркемнәрен лексик-грамматик мәгънәсе, морфологик һәм синтаксик билгеләре буенча аера һәм аларны таный белү. Морфологик анализ ясау.

2. Өйрәнелгән сүз төркемнәре белән җөмләләр һәм текстлар төзү. Сүз төркемнәренең төрле ысуллар белән ясалышын белү.

*Гади җөмлә синтаксисы һәм пунктуациясе:*

1. Сүзтезмәләргә, гади җөмләләргә синтаксик анализ ясый белү.
2. Җөмләнең баш кисәкләрен, иярчен кисәкләрен табып , аларның нинди сүз төркеме белән белдерелүен әйтү .Ия белән хәбәр янында сызык кую очракларын белү.
3. Сүзтезмәне җөмләдән аера белү. Сүз төркеме белән җөмлә кисәген дөрес билгеләү.
4. Аерымланган җөмлә кисәкләре, эндәш һәм кереш сүзләр кергән җөмләләр төзү. Аерымланган хәлләр, аерымланган аныклагычлар, эндәш, кереш сүзләр янында тыныш билгеләрен куя белү.
5. Туры һәм кыек сөйләмне дөрес куллану, алар кергән җөмләләр төзү.Диолог, туры һәм кыек сөйләм янында тыныш билгеләрен куя белү.
6. Җөмләнең әйтү максаты ягыннан төрен, интонация, логик басым һәм сүз тәртибен белү. Җөмлә ахырында тыныш билгеләрен куя белү.
7. Тиңдәш кисәкләрне билгеләү, алар янында тыныш билгеләрен дөрес куллану.

Сөйләм эшчәнлеге:

1. Эш кәгазьләреннән әдәби әсәр героена адресланган хат язу, әдәби геройларга характеристика язарга өйрәнү.
2. Укучыларның, үз тәҗрибәләреннән чыгып, диалогик һәм монологик сөйләм оештыра белүе. Хикәяләр язу.
3. Грамматик биремле контроль диктантлар, төрле типтагы диктантлар язу(85-110сүз).
4. Сочинение элементлары булган изложениеләр язу(270-350, 125-135)
5. Татар телендәге сүз тәртибе үзенчәлекләрен чагылдырган кыска текстларны тәрҗемә итү күнегүләре үтәү.
6. Бирелгән план буенча сочинениеләр язу(2-2,5 бит)

## Укыту предметының укыту планында тоткан урыны

Укыту планында 6 нчы сыйныфта татар теленнән атнага 1 сәгать вакыт бирелә. Татар теленнән тематик планны “Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы (татар балалары өчен): 1-11 сыйныфлар.”на (Ф.Ф.Харисов, Ч.М. Харисова,В.А. Гарипова, Р.Р. Җамалетдинов, Р.Ф.Җамалетдинова. Казан. “Мәгариф” нәшрияты, 2010.) нигезләнеп төзедем. Программада 34 сәгать каралган.

Гомумбелем күнекмәләрен бәяләүнең критерийлары һәм нормалары

<u>Язма эшләрнең күләме һәм аларны бәяләү:</u>

Контроль диктант - ел башында 105-120 сүз,  ел ахырында 115-125 сүз

Контроль диктантны бәяләү:

1. Эш пөхтә башкарылса, хатасы булмаган эшкә “5” ле куела. (Бер – орфографик, ике пунктуацион хата булырга мөмкин.)
2. Ике орфографик, ике пунктуацион яки бер орфографик, дүрт пунктуацион хаталы эшкә “4” куела.
3. Дүрт орфографик, дүрт пунктуацион яки өч орфографик, алты пунктуацион хаталы эшкә “3” куела.
4. Алты орфографик, биш пунктуацион яки биш орфографик, сигез пунктуацион хаталы эшкә “2” куела.

Изложение текстының күләме
ел башында 350-370 сүз (135-140 - язма күләме)
ел ахырында сүз 370-390(140-145 язма күләме)
Изложениене бәяләү
1. Тема тулысынча ачылган, фактик һәм техник хаталары булмаган, стиль бердәмлеге сакланган эшкә «5» ле куела. (Бер орфографик, ике пунктуацион яки ике грамматик хатасы булырга мөмкин.)
2. Текстның эчтәлеге темага нигездә туры килсә, фикерне белдерүдә зур булмаган ялгышлыклар җибәрелсә, бер-ике фактик, бер-ике техник хатасы булса, ике орфографик, ике-өч пунктуацион, бер грамматик хатасы булган эшкә «4» ле куела.
3. Язмада эчтәлек эзлекле бирелмәсә, стиль бердәмлеге сакланмаса, өч фактик, ике-өч техник хатасы булса, өч орфографик, дүрт пунктуацион, ике грамматик хатасы булган эшкә «3» ле куела.
4. Эзлеклелек, стиль бердәмлеге сакланмаса, язма эш планга туры килмәсә, фактик һәм техник хаталары күп булса, орфографик хаталарның саны дүрттән, пунктуацион хаталарның саны биштән, грамматик хаталар саны өчтән артса, «2» ле куела.

Сочинениенең күләме һәм аны бәяләү

Иҗади эшнең бер төре буларак, сочинение — укучының язма рәвештә үти торган эше. Ул бәйләнешле сөйләм үстерү күнекмәләре булдыруда зур әһәмияткә ия. Әдәби (хикәяләү, очерк, истәлек, хат, рецензия һ. б.), әдәби-иҗади, өйрәтү характерындагы, ирекле, рәсемнәр нигезендә үткәрелә торган һәм контроль сочинениеләр була.

Сочинениене бәяләү
1. Язманың эчтәлеге темага тулысынча туры килсә, фактик ялгышлары булмаса, бай телдә, образлы итеп язылса, стиль бердәмлеге сакланса, «5» ле куела. (Бер орфографик яисә ике пунктуацион (грамматик) хата булырга мөмкин.)
2. Язманың эчтәлеге нигездә темага туры килсә, хикәяләүдә зур булмаган ялгышлыклар күзәтелсә, бер-ике фактик хата җибәрелсә, теле бай, стиль ягы камил булып, ике орфографик, өч пунктуацион (грамматик) яисә бер-ике сөйләм ялгышы булса, «4» ле куела.

3. Эчтәлекне бирүдә җитди ялгышлар, аерым фактик төгәлсезлекләр булса, хикәяләүдә эзлеклелек югалса, сүзлек байлыгы ярлы булса, стиль бердәмлеге дөрес сакланмаган җөмләләр очраса, өч орфографик, дүрт пунктуацион (грамматик) яисә өч-дүрт сөйләм хатасы булса, «3» ле куела.

4. Язма темага туры килмичә, фактик төгәлсезлекләр күп булып, план нигезендә язылмаса, сүзлек байлыгы бик ярлы булса, текст кыска һәм бер типтагы җөмләләрдән торып, сүзләр дөрес кулланылмаса, стиль бердәмлеге сакланмаса, биш орфографик, сигез пунктуацион (грамматик) яисә дүрт—алты сөйләм хатасы булса, «2» ле куела.

Укыту предметының сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча планлаштырылган нәтиҗәләре.

9нчы класс укучыларның белем дәрәҗәсенә таләпләр.

Фонетика:

1. Сузык һәм тартык авазларның классификациясен, алардагы үзгәрешләрне белү. Сингармонизм законын, рәт һәм ирен гармониясе үзенчәлекләрен сөйләмдә дөрес куллану.
2. Татар телендә иҗек калыплары, сүзләрне дөрес басым белән әйтү. Җөмләдә логик басымны дөрес билгеләү, тиешле интонация белән сөйләү.
3. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Алфавитны истә калдыру.
4. Сүзләргә фонетик анализ ясау.
5. Орфоэпик сүзлекләрдән файдалану.

Лексика һәм фразеология:

1. Татар теленең сүзлек составын килеп чыгуы, кулланылу өлкәсе һәм кулланылу дәрәҗәсе буенча бәяли белү.
2. Сүзләрне һәм фразеологизмнарны урынлы куллану, аларның мәгънәләренә аңлатма бирә белү. Синоним, омоним, антоним сүзләрне дөрес куллану.
3. Төрле типтагы сүзлекләрдән файдалана белү.

Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы:

1. Сүзләрнең мәгънәле кисәкләренә аңлатма бирә белү. Тамырдаш сүзләр табу. Сүзләрне төзелеше һәм ясалышы буенча тикшерү.
2. Татар телендә сүзләрнең ясалыш ысулларын белү.

Морфология:

1. Сүз төркемнәрен лексик-грамматик мәгънәсе, морфологик һәм синтаксик билгеләре буенча аера һәм аларны таный белү. Морфологик анализ ясау.
2. Өйрәнелгән сүз төркемнәре белән җөмләләр һәм текстлар төзү. Сүз төркемнәренең төрле ысуллар белән ясалышын белү.

Синтаксис:

1. Сүзтезмәләргә, гади һәм кушма җөмләләргә синтаксик анализ ясый белү.
2. Сүзтезмәләрне җөмләдән аера белү.Сүз төркеме белән җөмлә кисәген дөрес билгеләү.
3. Аерымланган җөмлә кисәкләре, эндәш һәм кереш сүзләр кергән җөмләләр төзү.
4. Туры һәм кыек сөйләмне дөрес куллану, алар кергән җөмләләр төзү.
5. Кушма җөмләләрнең схемасын төзү.
6. Текстның үзенчәлекле билгеләрен белү. Аның стилен дөрес куллану.
7. Җөмләдә сүз тәртибен билгеләү.

Пунктуация:

1. Җөмлә һәм текстта тыныш билгеләре куелырга тиешле урыннарны дөрес табу. Бирелгән җөмлә һәм текстта куелган тыныш билгеләренә аңлатма бирү.
2. Диолог, туры һәм кыек сөйләм янында тыныш билгеләрен куя белү.

Сөйләм эшчәнлеге:

1. Укучыларның, үз тәҗрибәләреннән чыгып, диалогик һәм монологик сөйләм оештыра белүе.
2. Укылган яки тыңланган текстның эчтәлеген сөйләү, план төзү.
3. Бирелгән план буенча сочинение язу.
4. Әдәби геройларны сурәтләп бирү.
5. Каралган спектакль буенча хикәя төзү (телдән яки язмача)
6. Программа буенча укылган китапның эчтәлеген сөйләү яки язу, үз фикереңне белдерү.
7. Эш кәгазьләре(гариза, белдерү, ышаныч кәгазе һ.б.) язу.
8. Якын дустыңа  яки туганыңа хат язу.
9. Укытучы биргән яки укучы үзе сайлаган китапка аннитация язу.
10. Сочинение элементлары булган изложение язу.
11. Стилистик хаталары булган җөмләләрне яки текстны төзәтү.
12. Татарчадан русчага яки русчадан татарчага тәрҗемә итү күнегүләре эшләү.

# Укыту предметының темаларга якынча бүленеше

| № | Дәреснең темасы | Сәг. сан. | Дәрес тибы | Укучылар эшчәнлегенә характеристика, эш төрләре | Контроль төрләре | Көтелгән нәтиҗә | Өй эше | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | план | факт |
| | Синтаксис буенча өйрәнгәннәрне искә төшерү | | | | | | | | |
| 1 | Синтаксис буенча 8 нче сыйныфта өйрәнгәннәрне кабатлау | 1 | Катнаш | Алдагы сыйныфларда үтелгәннәрне кабатлау (җөмлә, җөмлә кисәкләре, җөмләнең тиңдәш кисәкләре, җөмләнең аерымланган кисәкләре, кереш сүзләр, гади җөмләләрнең составы, әйтү максаты буенча төрләре) . Әңгәмә, укытучы сүзе, дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү. | 2 нче күнегүдә җөмләләрне җөмлә кисәкләре ягыыннан тикшерергә. | Җөмләләрне сүзләрдән һәм сүзтезмәләрдән аера белү, иярүче һәм ияртүче сүзне белүгә ирешү. Җөмләләрдә тыныш билгеләренең куелуын аңлатырга, җөмләгә синтаксик анализ ясый белергә, составы һәм әйтү максаты буенча төрен билгеләргә. | 4б. сорау. җавап бирергә | 08.09. | |
| | Кушма җөмлә синтаксисы һәм пунктуация | | | | | | | | |
| 3 | Гади һәм кушма җөмләләр. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Җөмләләрең уртак һәм аермалы яклары. Кушма җөмлә төзүче җөмләләрнең бер-берс бәйләнеше. Сорау-җавап эшчәнлегенә нигезләнеп, материалны аңлату, күнегүләр эшләү, проблемалы биремнәр, техник чараларны куллану, җөмләләр язу, логик фикер йөртү, чагыштыру, гомумиләштерү, анализ ясау | Дидактик материалдан мөстәкыйль эш. | Кушма җөмләләрне гади җөмләләрдән аера белү. | 14 нче күнегү, 10б. кагыйдә | 15.09. | |
| | | | Тезмә кушма җөмләләр | | | | | | |
| 5 | Тезмә кушма җөмләләрдә бәйләүче чаралар. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Тезмә кушма җөмләләр белән таныштыру. Укытучы аңлатуы, китап белән эш, тыңлау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү | Мөстәкыйль эш, 18 нче күнегү | Кушма җөмлә эчендәге гади җөмләләрнең бәйләүче чаралары буенча тезмә кушма җөмләләрнең төрен билгеләргә,тыныш билгеләренең куелуын аңлатырга. Җөмләнең тезмә кушма җөмлә икәнлеген билгеләү,бәйләүче чараларын күрсәтә белүгә ирешү, тыныш билгеләренең куелуын аңлату, җөмләнең схемасын төзү. | 19 нчы күнегү (телдән) 15-16б. кагыйдә | 22.09. | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 7 | Теркәгечле тезмә кушма җөмләләр. Алар янында тыныш билгеләре | 1 | Катнаш дәрес | Максатны, бурычларны әйтү, материалга кызыксыну уяту, сорау-җавап эшчәнлегенә нигезләнеп, материалны бирү, үрнәк буенча биремнәр эшләү ,логик фикер йөртү,анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау. Хаталарны төзәтү. | Теркәгечле тезмә кушма җөмләләр кулланып, “Туган тел” тур. хикәя язырга. | Җөмләнең теркәгечле тезмә кушма икәнлеген билгеләү.Тезмә кушма җөмләләрне сөйләмдә дөрес куллану. Теркәгечле тезмә кушма җөмләләрдә тыныш билгеләренең куелуын аңлату, җөмләнең схемасын төзү. | 17бит кагыйдә, 22нче күнегү | 29.09. | |
| 8 | Теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр. Алар янында тыныш бигеләре | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Укытучы аңлатуы, китап белән эш, тыңлау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү. Җөмләләр язу, логик фикер йөртү, чагыштыру,гомумиләштерү, анализ ясау | “Истәлекле көн” турын. кечкенә хикәя язырга | Җөмләнең теркәгечсез тезмә кушма җөмлә икәнлеген билгеләүгә ирешү. Теркәгечсез тезмә кушма җөмләләрдә тыныш билгеләренең куелуын аңлатуга, җөмләнең схемасын төзүгә ирешү | 19 бит. кагыйдә, 27нче күнегү | 06.10. | |
| 9 | Тезмә кушма җөмләләрне гомумиләштереп кабатлау. Синтаксик анализ ясау. | 1 | Белемнәрне гомумиләштереп кабатлау | Тезмә кушма җөмләләрне гомумиләштереп кабатлау.Эзләнү, тикшеренү методларын кулланып мөстәкыйль эшчәнлекне оештыру. Синтаксик анализ ясау. | Тест (15 мин) | Тезмә кушма җөмләләр турында алган белемнәрне ныгыту, синтаксик анализ ясау | 25нче күнегү | 13.10. | |
| | Иярченле кушма җөмләләр | | | | | | | | |
| 10 | Иярченле кушма җөмләләр.Баш һәм иярчен җөмләләр. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Иярченле кушма җөмләләр белән таныштыру. Укытучы аңлатуы, китап белән эш, тыңлау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү. | | Иярченле кушма җөмләнең төзелешен белүгә, баш һәм иярчен җөмләләрне таба белүгә ирешү.Күнегүләрдән иярченле кушма җөмләләрне табу, сорау куеп,баш һәм иярчен җөмләләрне билгеләү,бәйләүче чараларын табу, иярчен җөмләләрнең төзелеш ягыннан төрен билгели белү | 26-27б. кагыйдә, 36 нчы күнегү | 20.10. | |
| 11 | Аналитик иярчен җөмләләр, алар янында тыныш билгеләре. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Укытучы сүзе, дәреслек белән эш, танып белү активлыгын үстерү, эзләнү таләп итә торган мәсьәләләрне чишү юлларын үзләштерү, дидактик материал белән эш | 32 б. белемегезне тикшерегез.. | Тексттан аналитик иярченле кушма җөмләләрне таба белү ,бәйләүче чараларын билгеләү тыныш билгеләрен куя белүгә ирешү | 30бит кагыйдә, 40нчы күнегү | 27.10. | |
| 12 | Синтетик иярчен җөмләләр, алар янында тыныш билгеләре. | 1 | Яңа материалны өйрәтү. | Укытучы сүзе, дәреслек белән эш, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү, танып белү активлыгын үстерү, гомумиләштерү, анализ, нәтиҗә ясау | Сорауларга җавап бирегез, 36б. | Текстта синтетик иярченле кушма җөмләләрне таба белүгә,бәйләүче чараларын билгеләүгә,тыныш билгеләрен куя белүгә ирешү | 33-34бит кагыйдә, 45 нче күнегү | 10.11. | |
| 13 | Иярченле кушма җөмләләрнең синонимлыгы, рус телендә бирелеше | 1 | Катнаш | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү, танып белү активлыгын үстерү, кагыйдәләр белән эш. | . | Төзелешләре ягыннан төрле булган синонимик җөмләләр төзүгә, бер үк сүзләрдән торган җөмләләр арасыннан синонимик җөмләләрне табуга ирешү | 36-37б ит кагыйдә, 50 нче күнегү | 17.11. | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 14 | Һади Такташның тормыш юлы, иҗаты. «Мокамай» шигыре. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Һ. Такташның тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыру , сәнгатьле уку, анализ, тел-сурәтләү чараларын табу. | | Шагыйрьнең татар поэзиясендә торткан урынын билгели белү | 37-41 б. нче бит укырга. эчтәлек сөйләргә. | 24.11. | |
| 15 | Диктант. | 1 | Белем һәм күнекмәләрне тикшерү | Үз-үзеңә контроль ясау | диктант | Орфография һәм пунктуация кагыйдәләрен куллана белү. | | 01.12. | |
| | Иярчен җөмләләрнең мәгънә ягыннан төрләре | | | | | | | | |
| 15 | Иярчен җөмләләрнең мәгънә ягыннан төрләре. Хаталар өстендә эшләү. Иярчен ия һәм хәбәр җөмлә. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Биремнәрне эшләү (иҗади биремнәр), кереш күнегүләр, яңа материалны кабул итү Һәм аңлау, өйрәнү объекты буенча фикер йөртү. Хаталар өстендә эшләү. Иярчен ия һәм хәбәр җөмлә турында мәгълүмат бирү. Китап белән эш, тыңлау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү . | Белемегезне тикшерегез, 41б., сорауларга җавап бирергә. | Иярчен җөмләләрнең мәгънә ягыннан төрләрен, аның ничек билгеләнүен, татар һәм рус телләрендә иярчен җөмләләрнең мәгънә ягыннан төрләренең бер-берсенә туры килү-килмәвен белергә. Иярчен ия һәм хәбәр җөмләнең функцияләрен, сорауларын, бәйләүче чараларын белү, аналитик ия һәм синтетик ия җөмләсе булган җөмләләрне язу, иярчен хәбәр җөмләнең аналитик төре генә булуын, тыныш билгеләренең куелуын аңлатуга ирешү | 30-40 бит кагыйдә 52 нче Күнегү, кагыйдә | 08.12. | |
| 16 | Иярчен тәмамлык җөмлә. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Иярчен тәмамлык җөмлә җөмлә турында мәгълүмат бирү. Дәреслек, танып белү активлыгын үстерү, гомумиләштерү, анализ, нәтиҗә ясау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү . | Белемегезне тикшерегез, 47 б. сорауларга җавап бирегез | Иярчен тәмамлык җөмләнең функцияләрен, сорауларын, бәйләүче чараларын белү, аналитик ия һәм синтетик ия җөмләсе булган җөмләләрне язу,тыныш билгеләренең куелуын аңлатуга ирешү | 45бит кагыйдә 64 нче күнегү | 15.12. | |
| 17 | Иярчен аергыч җөмлә. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Укытучы сүзе, дәреслек, танып белү активлыгын үстерү, эзләнү таләп итә торган мәсьәләләрне чишү юлларын үзләштерү, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү . | Белемегезне тикшерегез, 50 б. сорауларга җавап бирегез | Иярчен аергыч җөмләнең функцияләрен, сорауларын, бәйләүче чараларын белү, аналитик ия һәм синтетик ия җөмләсе булган җөмләләрне язу, тыныш билгеләренең куелуын аңлатуга ирешү | 68 нче күнегү, 50бит сорау. җавап | 22.12. | |
| 18 | Иярчен вакыт һәм урын җөмләләр. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Иярчен вакыт һәм урын җөмләлә турында төшенчә бирү.Укытучы аңлатуы, китап белән эш, тыңлау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү | Белемегезне тикшерегез, 55 б. сорауларга җавап бирегез | Бирелгән җөмләләр арасыннан аналитик һәм синтетик иярчен вакыт, урын җөмләсе булган кушма җөмләләрне аерып чыгарып, бәйләүче чараларын күрсәтү, леше ягыннан төрен билгеләү, схемасын төзү. | кагыйдә, 72,75 нче күнегү | 29.12. | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 19 | Иярчен рәвеш һәм күләм җөмләләр. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Иярчен рәвеш һәм күләм җөмләләр турында төшенчә бирү.Укытучы аңлатуы, китап белән эш, тыңлау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү | | Бирелгән җөмләләр арасыннан аналитик һәм синтетик иярчен рәвеш һәм күләм җөмләсе булган кушма җөмләләрне аерып чыгарып, бәйләүче чараларын күрсәтү, төзелеше ягыннан төрен билгеләү, схемасын төзү | кагыйдә, 85нче күнегү | 19.01. | |
| 20 | Иярчен сәбәп һәм максат җөмләләр. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Укытучы сүзе, дәреслек белән эш, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү, танып белү активлыгын үстерү, гомумиләштерү, җөмләләр язу, анализ, тәрҗемә күнегүләре, нәтиҗә ясау | 89 нчы күнегү. Чагыштырып нәтиҗә ясарга | Бирелгән җөмләләр арасыннан аналитик һәм синтетик иярчен сәбәп һәм максат җөмләсе булган кушма җөмләләрне аерып чыгарып, бәйләүче чараларын күрсәтү, төзелеше ягыннан төрен билгеләү, схемасын төзү | кагыйдә, 87,91нче күнегү | 26.01. | |
| 21 | Иярчен шарт һәм кире җөмләләр. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Укытучы сүзе, дәреслек белән эш, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү танып белү активлыгын үстерү, гомумиләштерү, җөмләләр , анализ, нәтиҗә ясау | | Бирелгән җөмләләр арасыннан аналитик һәм синтетик иярчен шарт һәм кире җөмләсе булган кушма җөмләләрне аерып чыгарып,бәйләүче чараларын күрсәтү, төзелеше ягыннан төрен билгеләү,схемасын төзү | кагыйдә 100нче күнегү | 02.02. | |
| 22 | Иярченле кушма җөмләләрне кабатлау | 1 | Белемнәрне гомумиләштереп кабатлау | Алган белемнәрен гомумиләштереп кабатлау. Эзләнү, тикшеренү методларын кулланып мөстәкыйль эшчәнлекне оештыру . Җөмләләр язу, логик фикер йөртү, биремнәр эшләү , чагыштыру, гомумиләштерү, анализ ясау. | | Иярченле кушма җөмләләргә синтаксик анализ ясый белү, алар янында тыныш билгеләрен дөрес кую, сөйләмдә куллану | 107нче күнегү | 09.02. | |
| 23 | Хәсән Туфанның тормыш юлы, иҗаты. «Туган тел турында җырлар», «Кайсыгызның кулы җылы?», «Кем сез?» шигырьләре. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Хәсән Туфан тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыру, биографиясендәге әһәмиятле моментларны шигырьләре белән өлешчә ялгау, сәнгатьле уку, анализ | Иҗатын чорларга бүлү. | Иҗаты турында мәгълүмати булу, нәтиҗә ясый белү, үз мөнәсәбәтеңне белдерә алу, шигырьләрен анализлый алу. | 45-47нче би сәнгатьле укырга, "Туган тел турында җырлар " ятларга | 16.02. | |
| | | | Катлаулы кушма җөмләләр | | | | | | |
| 24 | Күп тезмәле кушма җөмлә.Хаталар өстендә эшләү | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Укытучы сүзе, дәреслек, танып белү активлыгын үстерү, эзләнү таләп итә торган мәсьәләләрне чишү юлларын үзләштерү, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү. | | Күп тезмәле кушма җөмләләр һәм аларга анализ ясау тәртибе белән танышу, күп тезмәле кушма җөмләләр төзүгә ирешү | 77бит кагыйдә, 1 җөмлә уйлап яз., синт. анализ яс. | 02.03. | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 25 | Тиңдәш иярүле күп иярченле кушма җөмлә<br>Тиңдәш түгел иярүле күп иярченле кушма җөмлә | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Сорау-җавап эшчәнлегенә нигезләнеп, материалны аңлату, күнегүләр эшләү, проблемалы биремнәр, сүзлек белән эш, логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, дәреслек, дидактик материал белән эш. Материалны аңлату, дәреслек белән эш, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү, танып белү активлыгын үстерү, гомумиләштерү, анализ, нәтиҗә ясау | Искәртмәле диктант, схемаларын төзергә. | Бирелгән җөмләләр арасыннан күп иярченле кушма җөмләләрне аерып чыгарып, схемасын төзү. Тиңдәш иярүле күп иярченле куш-Ма җөмләләр белән танышу, аларның схемасын төзү.<br>Тиңдәш түгел иярүле күп иярчен-ле кушма җөмләләр белән танышу, аларның схемасын төзү. | 119нчы күнегү 121нче күнегү | 09.03. | |
| 26 | Бер-бер артлы иярүле күп иярченле кушма җөмлә | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Материалны аңлату, дәреслек белән эш, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү, танып белү активлыгын үстерү, гомумиләштерү, анализ, нәтиҗә ясау | Кушма җөмләләрнең схемасын төзү | Бер артлы иярүле, күп иярченле кушма җөмләләр белән танышу, аларның схемасын төзү. | Җөмләләр-нең схемала-рын төзергә | 16.03. | |
| 27 | Берничә төр иярүле күп иярченле кушма җөмлә. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Укытучы сүзе, дәреслек, танып белү активлыгын үстерү, эзләнү таләп итә торган мәсьәләләрне чишү юлларын үзләштерү, дидактик материал белән эш | Белемегезне тикшерегез, 84 б. сорау-ларга җавап бирегез | Берничә төр иярүле күп иярченле кушма җөмләләр белән танышу, аларның схемасын төзү. | 123 нче күнегү | 23.03. | |
| 28 | Катнаш кушма җөмләләр турында төшенчә<br>Җөмләләргә синтаксик анализ. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Укытучы аңлатуы, китап белән эш, тың-лау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү, җөмләләргә синтаксик анализ. | | Сөйләмдә катнаш кушма җөмлә-ләрне куллану. Бирелгән җөмләләр арасыннан катнаш кушма җөмлә-ләрне аерып чыгарып, семасын төзү. | 84бит кагыйдә, 126нчы күнегү | 06.04. | |
| 29 | Кушма җөмлә синтаксисы һәм анда кулланылучы тыныш билгеләрен гомумиләш-тереп кабатлау | 1 | Белемнәрне гомумиләште реп кабатлау | Алган белемнәрен гомумиләштереп кабатлау. Эзләнү, тикшеренү методларын кулланып мөстәкыйль эшчәнлекне оешты-ру | Белемегезне тикшерегез, 85б. сорау-ларга җавап | Гади җөмләләре үзара тезү юлы белән дә, ияртү юлы белән дә бәйләнгән катнаш кушма җөмлә-ләргә синтаксик анализ ясау | 132 нче күнегү | 13.04. | |
| 30 | Илдар Юзеевның тормыш юлы, иҗаты. «Таныш моңнар» әсәре. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Поэманың эчтәлеген, төзелешен (тема, идея, сюжет, композиция, образлар системасы) анализлый белү, логик фикерләү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, тел сурәт-ләү чараларын табу, сәнгатьле уку | Сорауларга җавап, укучы нәтиҗәсе. | Язучының тормыш юлы һәм иҗаты турында тулырак мәгълүмат бирә белү,әңгәмәдә катнаша алу, нәтиҗә ясый белү, үз мөнәсәбәтеңне белдерә алу. | 145-154 б. укырга, эчтәлек сөйләргә. | 20.04. | |
| | | Текст синтаксисы һәм пунктуация | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 31 | Текст синтаксисы турында төшенчә. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Текстның бер төре буларак тезем, Чит сөйләмле текст турында белешмә бирү. Укытучы сүзе, дәреслек белән эш, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү, танып белү активлыгын үстерү, гомумиләштерү, анализ, нәтиҗә ясау Тезем һәм чит сөйләмле текст белән танышу. | Белемегезне тикшерегез, 94 б. сорауларга җавап | Тиңдәш кисәкләре яки тиңдәш җөмләләре күп булу нәтиҗәсендә бик нык җәенкеләндерелгән гади яки кушма җөмләнең тезем булуына төшендерү. Бүлемнәрен, нинди интонация белән укылуын, сызыкның кайсы урынында куелуын аңлатуга ирешү Чит сөйләмле текст белән танышу. | 90-92бит кагыйдә, 94нче бит, сорау. җавап | 04.04. | |
| 32 | Туры сөйләм янында тыныш билгеләре | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Туры сөйләмне кыек сөйләмгә, кыек сөйләм сөйләмгә әйләндерү, тыныш билгеләрен кую, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү. | Схемаларга туры китереп җөмләләр язарга. | Туры сөйләмне кыек сөйләмгә, кые сөйләмне туры сөйләмгә әйләндеру билгеләрен кую. Барлык төр җөмлә дә тыныш билгеләрен куя белү | 96бит кагыйдә, 140нчы күнегү | 11.05. | |
| 33 | Пунктуация турында гомуми төшенчә. Тыныш билгеләрен төркемләү. | 1 | Катнаш дәрес | Укытучы сүзе, дәреслек, танып белү активлыгын үстерү, күнегүләр эшләү, проблемалы биремнәр, сүзлек белән эш, аерым төшенчәләр өстендә эш, төп фикерне аера белү, бергәләп уйлау, бәхәс алып бару, дәлилләү | | Тыныш билгеләрен кую турындагы кагыйдәләр җыелмасын пунктуация дип аталуын искәртү, төрлечә классификацияләп йөртелүен белү | 99-100бит кагыйдә, | 18.05. | |
| 34 | Диктант. | 1 | Белемнәрне гомумиләштереп кабатлау | Үз-үзеңә контроль ясау | диктант | Орфография һәм пунктуация кагыйдәләрен куллана белү. | | 25.05. | |

## Укытуны материаль-техник һәм мәгълүмати яктан тәэмин итү

Татар теленә өйрәткәндә, түбәндәге материаль-техник чаралардан файдалану таләп ителә:

- күрсәтмә әсбаплар;
- белешмә материаллар;
- аудио һәм видео әсбаплар;
- компьютер программалары;
- электрон китапханә;
- татар сайтлары (belem.ru; tatarile.org.com);

Укыту – методик комплекты


1. Дәреслек *:* К.З.Зиннәтуллина, Ф.Ф.Фатыйхова, Р.Х.Мирзаһитов Татар теле ( рус урта гомуми белем мәктәбенең 9 нчы сыйныфында укучы татар балалары өчен дәреслек ) Казан “Мәгариф” 2011 нче ел.
2. Татар теле морфологиясе. Ф.М. Хисамова.- Казан, “Мәгариф”, 2005.
3. Хәзерге татар әдәби теле Ф.С.Сафиуллина, М.З.Зәкиев. – Казан, “Мәгариф”, 1994.
4. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. Ф.С.Вәлиева, Г.Ф.Саттаров.-Казан:”Раннур”, 2000.
5. Татар теленнән күнегүләр һәм тестлар. Ф.Ф.Харисов, Ч.М.Харисова. Казан, “Яңалиф”, 2006.

6. Татар теленнән тестлар. Н.В.Максимов. Казан, “Мәгариф”, 2002, 2008.
7. Изложениеләр җыентыгы. Казан, “Мәгариф”, 2003.
8. V-XI сыйныфлар өчен язма эшләр. З.Н.Хәбибуллина, М.А. Вәлиуллин, Х.Г.Фәрдиева. Казан, “Мәгариф”, 2003.